СОВЕТ СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Суксу, ул. Школьная, 9а

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 август 2021 ел** **№ 35**

## Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында Федераль законнар, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендәге 168 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Советның 12.02.2020 №181, 19.11.2020 №12 карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылуы яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте, гражданлыгын (подданствосын), аның нигезендә чит ил дәүләте гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, туктату турында муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил дәүләте - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил дәүләте, гражданлыгы (подданствосы), аның нигезендә чит ил дәүләте гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт белән тулыландырырга:

«9.1) чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) алуы яисә яшәүгә рөхсәт яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган очракта, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) алынган, яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка

документ алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

2) 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;»;

б) 1 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев